**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5740**
**02.11.2020**

Башкарма комитетның 2013 елның 20 сентябрендәге 5735 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 20 сентябрендәге 5735 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3276 номерлы, 2018 елның 25 апрелендәге 2307 номерлы, 2018 елның 5 июнендәге 3223 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6591 номерлы, 2019 елның 20 мартындагы 1375 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 3046 номерлы, 2019 елның 5 декабрендәге 6344 номерлы, 2020 елның 14 апрелендәге 1826 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 пунктның икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алыналар:

- аерым затның ул ия булган (булучы) күчемсез милек объектларына хокуклары турында, Россия Федерациясе территориясендә күчемсез милек объектларын тартып алу буенча килешүләрне гамәлгә ашыру турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән белешмәләр), 2000 елның 1 гыйнварыннан соңгы чор өчен – яшь гаиләнең барлык әгъзаларына;

- күчемсез милек объектына хокуклар күчү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә»;

2) 3.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Идарә белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша аерым затның ул ия булган (булучы) күчемсез милек объектларына хокуклары турында, Россия Федерациясе территориясендә күчемсез милек объектларын тартып алу буенча килешүләрне гамәлгә ашыру турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән белешмәләр) бирү хакында запрос җибәрә, 2000 елның 1 гыйнварыннан соңгы чор өчен – яшь гаиләнең барлык әгъзаларына.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов